ГЛАВА ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

______________ с. Верхний Услон ______________

75, 13.11.2015

«2016 елга Югары Ослан муниципаль районы бюджеты турында» Югары Ослан муниципаль районы Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында

Югары Ослан муниципаль районында яшәүчеләрнең "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм "Югары Ослан муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставының 15 статьясы нигезендә халык алдында тыңлаулар үткәрү юлы белән 2016 елга Югары Ослан муниципаль районы бюджеты проектын тикшерүдә катнашу хокукларын үтәү максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Советының «2016 елга Югары Ослан муниципаль районы бюджеты турында»гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Үткәрү датасы һәм вакыты - 2015 елның 25 ноябрендә 10.00 сәгатьтә;

2.2. үткәрү срогы - 1 көн;

2.3. Үткәрү урыны - Ю.Ослан авылы, Чехов ур., 18 йорт Югары Ослан муниципаль районы Советының утырышлар залында;

2.4. Аның буенча фикер алыша торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр бирелергә мөмкин, гавами тыңлауларда чыгыш хокукы белән катнашуга заявкалар бирелергә гариза язарга мөмкин булган адрес, Югары Ослан авылы Чехов ур. 18, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге начальнигы Александрова В.Н.(эш көннәрендә - 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр)

2.5. гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар тапшыру срогы - 2013 елның 16 ноябренә кадәр (тел 2-23-15).

3. Югары Ослан районының Башкарма комитетына:

3.1.Югары Ослан муниципаль районы Советының "2016 елга Югары Ослан муниципаль районы бюджеты турында" гы карары проекты буенча гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда ачык тыңлауларны әзерләргә һәм уздырырга;

3.2.халык алдында тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре буенча Югары Ослан муниципаль районы Советына халык алдында тыңлауларның беркетмәсен, халык алдында тыңлауларның тәкъдимнәрен, халык алдында тыңлауларның нәтиҗәләре буенча бәяләмәне, шулай ук 2016 елга Югары Ослан муниципаль районы бюджетының эшләп бетерелгән (үзгәрешләр кертелгән очракта) проектын тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны, Югары Ослан муниципаль район Советының «Югары Ослан муниципаль районының 2016 елга бюджеты турында» карар проектын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы башлыгының урынбасары С.В. Осянинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы М.Г. Зиатдинов